**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында электр тәэминаты куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча штаб төзү турында» 2008 елның 12 июлендәге ПУ-324 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 27 ноябрендәге ПУ-615 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-209 номерлы, 2009 елның 13 ноябрендәге ПУ-605 номерлы, 2010 елның 1 февралендәге ПУ-36 номерлы, 2010 елның 20 августындагы ПУ-546 номерлы, 2011 елның 7 февралендәге ПУ-48 номерлы, 2013 елның 16 декабрендәге ПУ-1233 номерлы, 2014 елның 8 ноябрендәге ПУ-1023 номерлы, 2016 елның 23 гыйнварындагы ПУ-26 номерлы һәм 2016 елның 13 октябрендәге ПУ-917 номерлы, 2017 елның 20 гыйнварындагы ПУ-39 номерлы, 2017 елның 8 июнендәге ПУ-480 номерлы һәм 2018 елның 3 маендагы ПУ-348 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында электр тәэминаты куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча штаб (алга таба – Штаб) составына, Штаб әгъзасы Р.Җ. Хәбибуллинның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә: «Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы (килешү буенча)».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, дәүләт контролен (күзәтчелеген) тормышка ашыручы федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеген оештыру мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында» 2013 елның 24 маендагы ПУ-445 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 24 июлендәге ПУ-689 номерлы, 2014 елның 18 апрелендәге ПУ-378 номерлы, 2015 елның 14 ноябрендәге ПУ-1094 номерлы, 2017 елның 9 июнендәге ПУ-490 номерлы һәм 2018 елның 19 февралендәге ПУ-178 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, дәүләт контролен (күзәтчелеген)

тормышка ашыручы федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеген оештыру мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан В.К. Козонковны чыгарырга;

б) Комиссия составына Демидов Сергей Анатольевичны – «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгын (килешү буенча) кертергә;

в) Комиссия әгъзасы Р.Җ. Хәбибуллинның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы (килешү буенча)».

3. Татарстан Республикасы Президентының «Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул иткән көненә багышланган «Изге Болгар җыены» тантаналы чарасын әзерләү һәм үткәрүне оештыру турында» 2017 елның 21 августындагы ПУ-718 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 14 апрелендәге ПУ-314 номерлы һәм 2018 елның 6 июлендәге ПУ-473 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул иткән көненә багышланган «Изге Болгар җыены» тантаналы чарасын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) составына, оештыру комитеты әгъзасы Р.Җ. Хәбибуллинның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә: «Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы (килешү буенча)».

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 19 декабрь
№ ПУ-864